Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР №10-1

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 6 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында»2017 елның 1 августындагы 2-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфа окладлары күләмнәрен индексацияләү турында»28.07.2017 ел, №525 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләмнәрен, ай саен өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 1 августындагы 2-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карар кушымтасы нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына җибәрергә.

4. Карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе штп.,Ленин урамы, 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-

sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башлыгы И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 01.03.2017 №2-1 карары карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 06.10.2017 № 10-1 карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләме**

| № п/п | Эш исемнәре | Хезмәт хакы, сум. |
|---|---|---|
| | | 10 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 3921 |
| 2. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 3680 |
| 3. | Әйдәп баручы белгеч | 2873 |

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен билгеләү өчен тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен хезмәт өчен түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.

Күрсәтелгән күрсәткечләргә карап, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге (халык саны 5 меңнән 10 меңгә кадәр) унынчы төркемгә кертелгән.